СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: .Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 2-35

Карар
от 24.09.2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Никифорово авыл җирлеге башкарма комитетының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 7 номерлы карары, Никифорово авыл җирлеге Советының "Референдум уздыру инициативасы турында" 2018 нче елнын 17 че сентябрендә кабул ителгән 6-36 номерлы карары, Никифорово авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре" 2014 нче елның 2 че апрелендә кабул ителгән 2-33 номерлы (17 сентябрь 2018 ел №5-34 редакциясендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында

хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне , су чыгаруны оештыру, ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

- Сәртек т. п. су чыганагында павильон коймасы ясау һәм урнаштыру;

2.Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

– Никифорово торак пунктында-Пролетар урамында, Карл Маркс урамында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау;

- Сәртек торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Никифорово авылы юлларын тигезләү һәм кардан чистарту;

| | |
|---|---|
| « ӘЙЕ » | « ЮК » |

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Степанов С.Н./